РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«22» сентябрь 2021 ел Олы Кайбыч ав. № 63

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2019 елның 23 сентябрендәге 184 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 31 июлендәге 293-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 02 июлендәге 352-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2019 елның 23 сентябрендәге 184 номерлы«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» (2019 елның 30 декабрендәге 206 номерлы үзгәрешләр белән) карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планына (программасына) кертелгән унитар предприятиеләр, акционер җәмгыятьләр һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр Палатага Россия Федерациясенең бухгалтерлык исәбе турындагы законнарында билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән предприятиеләр һәм җәмгыятьләр «Бухгалтерлык хисабы турында» 2011 елның 6 декабрендәге 402-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясында каралган бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсын формалаштыру максатларында мондый хисаплылыкны тапшыру бурычыннан азат ителгән очракта, күрсәтелгән предприятиеләр һәм җәмгыятьләр квартал, яртыеллык, тугыз ай өчен арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын тапшыру өчен билгеләнгән срокта, хисап чоры тәмамланган көннән алып утыз көннән дә соңга калмыйча, күрсәтелгән хисаплылыктагы мәгълүматны Кайбыч муниципаль районының Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге

http:/kaybici.tatarstan.ru// веб-адрес буенча рәсми сайтында урнаштырып, еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын тапшыра.

Күрсәтелгән предприятиеләр һәм җәмгыять бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсын формалаштыру максатларында еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын биргән очракта, вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы әлеге дәүләт мәгълүмат ресурсыннан ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасын кулланып шундый хисап ала.»;

9.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.1. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү дигәндә хосусыйлаштыру турындагы мәгълүматтан затларның чикләнмәгән даирәсеннән ирекле файдалана алу мөмкинлеген булдыруга юнәлдерелгән һәм «Интернет» челтәрендә дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планнарын (программаларын), тиешенчә дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарларны, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне сату турында һәм аны сату йомгаклары турындагы мәгълүмати хәбәрләрне, федераль мөлкәтне хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турындагы еллык хисапларны, Россия Федерациясе субъектлары милкендәге, муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турындагы хисапларны үз эченә ала торган чаралар аңлашыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында мәгълүмат урнаштыру өчен «Интернет» челтәрендә рәсми сайт булып Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән торглар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты (алга таба - «Интернет» челтәрендә рәсми сайт) тора.»;

9.5. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.5. Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планнарына (программаларына) кертелгән объектларга карата хосусыйлаштырыла торган мөлкәтне сатуны оештыру һәм (яисә) сатучы функциясен гамәлгә ашыру өчен җәлеп ителә торган юридик зат өстәмә мәгълүмат белән тәэминителергә мөмкин.».

2. Әлеге карар, 2022 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктның 1.1 пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгы А. И. Рәхмәтуллин